УДК 37.018.76:398

# ХАЛЫК ПЕДАГОГИКАСЫ – МИЛЛИ ҮЗАҢ ТӘРБИЯЛӘҮ ЧАРАСЫ

***Л.И. Яруллина***

*Институт истории им. Ш.Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*liysan-jarullina@mail.ru*

Мәкаләдә халык педагогикасының милли тәрбия бирүдәге роле анализлана. Хезмәттә галимнәрнең «этнопедагогика», «халык педагогикасы», «милли тәрбия», «милли үзаң» төшенчәләренә булган карашлары тикшерелә, бу юнәлештәге эзләнү-тикшеренүләрнең әһәмиятле булуына басым ясала. Автор, бу күренешләрнең күпкырлы һәм күпаспектлы булуын истә тоткан хәлдә, милли үзаңны формалаштыруда катнашучы төп факторлар буларак фольклорны, акыл, рухи, эстетик, хезмәт, физик һәм дини тәрбияне күрсәтә, һәрьяклап үсешкә ирешкән шәхесне тәрбияләүдә комплекслы якын килергә кирәклекне ассызыклый.

**Төп төшенчәләр:** халык педагогикасы, этнопедагогика, милли үзаң, рухи кыйммәтләр, халык авыз иҗаты (фольклор), рухи, акыл, дини, хезмәт, милли тәрбия, эмпирик белемнәр, тәҗрибә.

Глобализация шартларында милли үзаңны саклап, милләтнең алгарышын тәэмин итүче, рухи-әхлакый мирасны буыннан-буынга тапшырылу юллары һәм ысуллары бүгенге педагогиканың иң актуаль мәсьәләләренең берсе дип әйтергә мөмкин. Бу табигый да, чөнки милләтнең заман таләпләренә җавап биреп, тиз үзгәрә торган дөньяда үз урынын табу сәләтенә ирешү халыкның гасырлар буе тупланып, камилләшеп килгән тәрбия ысулларыннан башка күз алдына китерү авыр. Шул исәптән, халык педагогикасы, милли тәрбия кешедә милли үзаң формалашу мөмкинлеген бирүче көчле корал булып санала.

Әлеге проблемага бәйле рәвештә, бүгенге көн педагогикасында «этнопедагогика», «халык педагогикасы», «милли тәрбия» кебек төшенчәләр торган саен актуальрәк яңгыраш ала. Бу юнәлештә күренекле педагог-галимнәрдән Я.И. Ханбиков, Ә.Н. Хуҗиәхмәтов, Ш.Ш. Җәләлиев, Д.И. Латышина, В.А. Николаев, И.П. Малютин, А.Ф. Хинтибидзе, Г.Н. Волков, А.Ш. Гашимов, В.Ф. Афанасьев, Г.Н. Филонов, А.Э. Измайлов, И. Сенигов һәм башкалар җитди тикшеренүләр алып бара.

Тәрбия – зур һәм киң төшенчә, ул акыл, физик, рухи, дини, хезмәт һәм башка аспектларны үз эченә ала. Яшьләр өлкән буын тарафыннан тупланган белем-тәҗрибәне, рухи кыйммәтләрне нәкъ менә тәрбия аша үзләштерә. Бу нисбәттән, баланы тәрбияләүдә, аның шәхес буларак

күпкырлы үсешендә милли тәрбиянең, халык педагогикасының роле әйтеп бетергесез зур.

«Халык педагогикасы» терминын педагогикага руслардан беренче булып К.Д. Ушинский кертеп җибәрә. Ул тәрбиянең көчен нәкъ менә аның халыкныкы булуында күрә [12, б. 252]. Ш.Ш. Җәләлиев фикеренчә, «халык педагогикасы ул – тәрбия өлкәсендә халыкта яшәп килгән карашлар, аның тәҗрибәгә нигезләнгән тәрбияләү, укыту алымнары һәм чаралары, буыннан-буынга күчеп камилләшкән педагогик белемнәре, халык өйрәтүләре, кыскасы, аның тәрбия тәҗрибәсе. Ул тәрбиянең халык ихтыяҗларына туры килердәй иң гуманлы һәм демократик идеалларын алга сөрә» [3, б. 5]. Р.Х. Шәймәрдәнов, Ә.Н. Хуҗиәхмәтовлар милли педагогикага «тормышта, тәрбия процессында сыналган, буыннан-буынга күчеп камилләшкән, милләт тарафыннан киң кулланылган тәҗрибәгә нигезләнгән укыту-тәрбия турындагы эмпирик гыйлемнәр җыелмасы» дигән билгеләмә бирәләр. Авторлар карашынча, анда милләтнең даими кулланган тәрбия алымнары, чаралары, ысуллары, чыганаклары, тәрбия карашлары, идеал һәм максатлары барысы бергә туплана [17, б. 6]. Г.Н. Волков халык педагогикасын халык авыз иҗатында, гореф-гадәт, йолаларда, балалар уеннарында, уенчыкларда сакланып калган педагогик мәгълүматлар һәм тәрбияви тәҗрибәнең бергәлеге рәвешендә күзаллый [2, б. 7]. А.Э. Измайлов халык педагогикасын тупланган һәм тикшерелгән эмпирик белемнәр җыелмасы, буыннан-буынга, нигездә, телдән тапшырылучы белем һәм күнекмәләр, халык массаларының тарихи һәм иҗтимагый тәҗрибәсе продукты дип билгели [5, б. 76]. Я.И.Ханбиков та халык педагогикасын эмпирик педагогик белемнәр һәм халык массаларының тәҗрибә өлкәсе рәвешендә характерлый [15, б. 16]. Халыкның тәҗрибә традицияләре, ди Г.Н. Волков, «фәнни аргументлар һәм раслаулар белән түгел, ә эш-хәрәкәт, эшчәнлек логикасы, тәрбияләнүчеләрнең психикасына тәэсир итү нәтиҗәләре һәм мең еллар дәвамында сайлап алынган һәм шомартылган әзер фикерләре белән кыйммәтле. Халык педагогикасының көче авторитетлы исемнәрдә һәм уңышлы теорияләрдә түгел, ә авторитетлы фикерләрдә һәм уңышлы нәтиҗәләрдә» [2, б. 7]. В.Ф. Афанасьев карашынча, халык педагогикасының асылын халыкның тормыш-көнкүреше өчен кирәк булган, практикада сыналган-тикшерелгән белемнәр суммасы тәшкил итә [1, б. 101].

«Халык педагогикасы» терминыннан тыш, педагогикада «этнопедагогика» төшенчәсе дә актив кулланылышта йөри. Этнопедагогика беренче тапкыр Г.Н. Волков тарафыннан 1960 нчы елларда кертелә һәм тиз арада популярлашып китә. Г.Н. Волков карашынча, «этнопедагогика» термины – тикшеренүләрдә этнографик материалның киң кулланылышын күрсәтүдә бик отышлы атама һәм ул әлеге фәннең асылын да яхшырак, төгәлрәк чагылдыра. «Этнопедагогика – халык массаларының үсеп килүче буынны тәрбияләүдәге тәҗрибәсе, аларның педагогик күзаллаулары, тормыш-көнкүреш, гаилә, ыру, кабилә, халык, милләт педагогикасы хакындагы

фән. Этнопедагогика тарихи шартлар тәэсирендә формалашкан, милли тәрбия системасы аркасында сакланып калган, эволюция кичерүче милли характердагы үзенчәлекләрне өйрәнә» [2, б. 30–31].

Фәндә этнопедагогиканың өйрәнү объекты буенча да фикер төрлелеге күзәтелә. Мисал өчен, Э.Р. Хәкимов этнопедагогика фәненең өйрәнү объекты буларак махсус юнәлтелгән һәм стихияле баручы этнопедагогик белем бирү процессын күрсәтсә [13, б. 39–52], Г.В. Нездемковская этнопедагогиканың өйрәнү предметы буларак бары халыкның традицион тәрбиясен киң иҗтимагый-педагогик мәгънәдә күрсәтүне генә дөрес дип таба [10, б. 186]. Г.Н. Волков хезмәтләрендә әлеге категория тагын да күләмле, гомуми яңгыраш ала. Аның уйлавынча, этнопедагогиканың объекты – тормыш-чынбарлыкта реаль яшәеш алган халык мәдәнияте һәм халык педагогикасы [2, б. 13].

Халык педагогикасының концептуаль мәсьәләләре Ш.А. Мирзоев тарафыннан да өйрәнелә. Автор хезмәтләрендә халык тәрбиясенең иң мөһим факторы буларак туган телгә басым ясый [8, б. 58].

Ф.Г. Ялалов белем бирүне этнопедагогикалаштыру дигәндә, халыкның белем һәм тәрбия бирүдәге уңай тәҗрибәсен тирәнтен өйрәнү һәм аны хәзерге шартларда иҗади куллану процессын күздә тота [19, б. 10].

Шул рәвешчә, этнопедагогика тарихи шартлар тәэсирендә формалашкан милли үзенчәлекләрне өйрәнә, ул – теоретик фикерләү өлкәсе, фән тармагы. Халык педагогикасы исә, халык тәрбиясендәге идеяләр һәм чаралар, тәрбия тәҗрибәсе кебек төшенчәләрне үз эченә ала. Халык педагогикасы халыкның тормыш-көнкүрешендәге тәрбия традицияләрендә урын ала. Ягъни бу термин белән халыкның буыннан-буынга, чордан-чорга тапшырылып килүче тәрбия ысуллары һәм чаралары атала. Этнопедагогикага исә, фән тармагы буларак, гомумиләштерү, системалаштыру кебек сыйфатлар хас. Ул – халыкның тәрбия өлкәсендәге эмпирик белемнәр җыелмасын, тәҗрибәсен системага салып, теоретик яктан өйрәнүче фән.

Милли үзаң орлыгы балага бишектә ятканда ук салына. Бала белән туган телдә сөйләшү, беренче бишек җырлары, шигырьләр – болар барысы да әлеге орлыкның шытып үсүенә һәм формалаша башлавына китерә. Алга таба әлеге үсентенең никадәр көчле, тамырларының никадәр нык булуы, иң беренче чиратта, гаиләдәге милли тәрбиянең куелышы белән бәйле, әлбәттә. Өлкән буын үзенә йөкләнгән бу җаваплылыкны аңларга, ачык тоярга һәм бу процесста халык педагогикасы һәм милли тәрбиянең төп, һәлиткеч чара булуын яхшы күзалларга тиеш.

Милли үзаң формалашу кешедә гомер буена бара торган процесс, чөнки инсанның дөньяны танып-белү, акыл һәм гыйлем туплау эшчәнлегендә милли үзаң төрле төсмерләр белән байый, тагын да тирәнәя төшә. Шуңа күрә «милли үзаң» күпкырлы, киңаспектлы катлаулы төшенчә буларак күзаллана. Ул «кешенең кайсы милләт вәкиле, ул нинди милләт, аның үзенчәлекләре, психологиясе, менталитеты, тарихы, кыйбла (ыруг, кабилә, дин) бәйләнешләре, гореф-гадәт, йолалары, дине, теле, матди һәм

рухи мәдәниятен, көнкүрешне оештыру тәртибен, халык авыз иҗатын, азык-төлеген, кием-салымын һ.б.ларны үз эченә ала» [17, б. 13].

Халык педагогикасы тәҗрибәгә нигезләнә. Әле язу – әлифба уйлап табылганчы ук халыкның үз тәрбия тәҗрибәсе, үзенчәлекле әхлак тәртипләре, рухи-мәдәни хәзинәләре туплана башлый. Кеше тормышын матурлый, аны тәрбияле, шәфкатьле итә торган йолалар арта, традицияләр ныгый. Рухи тормышның нигезе, аның башы хезмәттә, табигатьтә, рухи талантта, табигыйлектә һәм кешелеклектә иканлеге күренә [3, б. 7].

Билгеле ки, кешедә милли үзаң тәрбияләү, беренче чиратта, аның туган теле нигезендә барырга тиеш. Адәм баласы үзенең нинди кавемнән, нинди милләттән булуы, үзенең кемлеге хакында мәгълүматны туган телендә алганда аны калебенә һәм йөрәгенә сеңдерә алу сәләтенә ия. Бары туган телендә сөйләшкән, милли телен белгән инсан гына милләтенең дәвамчысы була ала.

Милли үзаңга нигез гаиләдә салына: «Ягъни үзенең кайсы кавем баласы, аның тарихы каян килә, кыйбласы кай тарафта, тугандаш кавемнәр кемнәр дигән сорауларга кешедә тәгаен-төгәл күзалланган җавап булырга тиеш» [17, б. 10]. Моны бары тик милли традицияләре булган, милли гореф-гадәтләрне саклаган, ана телендә сөйләшкән, өлкән буын белән тыгыз бәйләнештә торган, нәсел җебе нык булган гаилә генә тәэмин итә ала. Гаиләдә алган тәрбияне милли тәрбиягә нигезләнгән балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә көчәйтеп тулысынча формалаштырып кына була. Димәк, мәктәпләрдә милли педагогикага зур игътибар бирелү сорала һәм белем бирүнең федераль стандартлары бүген моңа мөмкинлек бирә.

Әйткәнебезчә, халык педагогикасы киңкырлы төшенчә буларак, үз эченә бик күп элементларны берләштерә. Болар – милли тәрбия процессы ысуллары, алымнары, гореф-гадәтләр, төрле күнекмәләр, халыкның педагогик карашлары, халык авыз иҗаты һ.б. Болар барысы да, теге яки бу күләмдә, яшь буында милли үзаң формалаштыруга хезмәт итә.

Татар халкының милли педагогикасында алар барысы да үз урынын алганнар: акыл, әхлак, зәвык, хезмәт, физик һәм дини тәрбия – болар барысы да яшь буында милли үзаңны тәрбияләүгә хезмәт итәләр. Татар халкы элек-электән хезмәт сөючәнлекне, әхлаклыкны, йөгерек акылны, тырышлыкны өстен күргән. Бала тугач та, ата-анасы, әби-бабайлары, өлкән кардәш-туганнары аны акрынлап әдәп-әхлакка, туган теленә, бераз үсә төшкәч, хезмәткә өйрәтә башлыйлар, гыйлемгә омтылыш тәрбиялиләр. Шунысын да ассызыклау мөһим: әлеге тәрбияләрне тормышка ашыруда халык авыз иҗаты әсәрләре (фольлор) аерым бер урында тора. Бу нисбәттән, әлеге өлкәдә эзләнүләр алып барган барлык педагоглар да халык педагогикасының, милли тәрбиянең нигезендә халык авыз иҗаты ята, дигән уртак фикергә киләләр (К.Д. Ушинский, Г.Тукай, А.З. Измайлов, Я.И. Ханбиков, Х.Ш. Мәхмүтов, Ф.С. Баязитова, Р.К. Уразманова, Р.А. Низамов, Җ.Г. Нигъмәтов һ.б.). Җырлар, тизәйткечләр, әйтемнәр, дастаннар, легендалар, эпослар, бәетләр, әкиятләр, мәкальләр, табышмаклар,

уеннар, мөнәҗәтләр, риваятьләр – болар барысы да фольклор жанрының эчтәлеген хасыйл итүче, зур тәрбияви көчкә ия берәмлекләр. Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре милләтебезнең гасырлар буена җыелып-тупланып килгән тормыш тәҗрибәсен, зирәклеген, акылын, халыкның рухи-әхлакый идеалларын үзләрендә чагылдыралар. К.Д. Ушинский әкиятләрне халыкның педагогик даһилыгын чагылдыручы буларак бәяләсә, Г.Тукай татар халык җырларына искиткеч зур бәя биреп: «... халык җырлары – безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр. ... Халык җырлары халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер», – дип яза. [11, б. 29]. Халык җырлары халыкның җанын, уй-хыялларын, милли рухын чагылдыручы буларак, зур тәрбияви көчкә ия. Аларда туган туфракка мәхәббәт тә, адәм баласын яшәтүче һәм көч бирүче өмет-хыяллар да, ата-анага зур хөрмәт тә, әхлакый кыйммәтләр дә – барысы да сыйган (Мәсәлән: *«Бик еракта идек без...», «Зиләйлүк», «Герман көе», «Ай былбылым», «Авыл көе», «Челтәр элдем читәнгә» һ.б.).*

Халык җырлары арасында «иң беренчел педагогик әсәр» [17, б. 25] буларак характерланган бишек җырлары ананың балага биргән беренче тәрбияви сабагы булып тора. Нәкъ менә бишек җырлары аша бала туган теленең моңы, көе белән таныша, үзенә аталган иң беренче изге теләкләрне ишетә, ананың чиксез мәхәббәтен тоя.

Халык авыз иҗатының мәрҗәннәре саналучы мәкаль-әйтемнәрдә теге яки бу халыкның яшәү мәсләге, аның төп кануннары, рухи-әхлакый йөзе чагыла. Бу уңайдан, татар халык мәкальләрен туплаган-барлаган Н. Исәнбәт тә мәкальләрнең, авыз иҗаты буларак, аталар сүзе яки халык хикмәте икәнлегенә, тәрбияви көче гаять зур булуга басым ясап, аларның тормышның һәртөрле җил-давыллары эчендә, безне аталарча кайгырткан өлкән һәм борынгы киңәшче; дөньяның әчесен-төчесен күп татыган, безгә дә аны ничек таныргa өйрәткән өлкән ага; безгә үзебезне һәм кешеләрне ничек сынарга өйрәткән сынаучы; безне хатага төшүдән алдан кисәтүче күрәзә; хатага төшсәң, ачы, туры иттереп, ләкин шул ук вакытта гадел һәм җылы рәвештә шелтә бирә белүче остаз; көнкүрештә һәртөрле мөнәсәбәтләрдә безгә булышчы иптәш; юлда ышанычлы юлдаш; безне эшкә, көрәшкә, актив булырга, ничек уңышка ирешергә чакырып торучы тәҗрибәле хәким; киңәшен, белем-тәҗрибәсен һич түләүсез чын күңелдән гүзәл мисаллар һәм матур тел белән әйтүче хикмәтле шагыйрь; безне дә үзе кебек дөньядан алданмыйча, озак һәм сәламәт яшәргә, ничек бәхетморатка ирешергә, үзе кебек яши белергә чакырган безнең күп гомерле һәм кара акылга бай карт; кыскасы, мәкальнең киң җәмәгатьчелек фикере, гомумхалык карашы, уртак акыл икәнлеген кат-кат ассызыклый. «Ул дәлил булып та, хөкем булып та, кәфил булып, кисәтүче яки гыйбрәт булып та, типик бер мисал булып та тормышның һәр ягына катышып, дөрес һәм гадел якны табарга, уртак мәслихәткә килергә, безне тоткарлыктан чыгарырга тырыша» [6, б. 226–227]. Автор фикеренчә, мәкальләр мәңге

яшь һәм тирән тормышлы халыкның үз йөрәгеннән, аның тел очыннан атылып чыккан шигъри хикмәтле, афористик әсәрләр булганга, туган телнең матурлыгын, тирән мәгънәләрне юраучанлык сәләтен балаларга сиздерү, йоктыру өчен балаларны мәкальләр белән дә тәрбия итәргә кирәк. Мәкальләр ата-баба мирасына хөрмәт белән карарга өйрәтә. Барлык шул нәрсәләр баланың үз акылы-фикере үсүдә үзенә генә бурычлы булмыйча, халыкның бүгенге һәм үткән тәҗрибәләренә, тел культураларына бурычлы булуын тойдырып, шулар аркылы аңарда илгә, Ватанга, халыкка мәхәббәт тойгылары тәрбия ителә

Татар халкы мәкальләре кеше тормышының күптөрле аспектларын колачлый: ата-ана, аларга хөрмәт; баланың холкы, аны тәрбияләп үстерү; сөйләү әдәбе; белем-гыйлемгә хөрмәт; кеше, аның рухи йөзе, әхлакы һ.б.: *Инсафлының теле саф. Аз сөйлә дә күп эшлә. Адәмне адәм иткән әдәп. Кеше күңеле пыяла, нык кагылсаң уала һ.б.*

Балаларның фикерләү сәләтен, тапкырлыгын үстерүдә татар халкының табышмаклары, сынамышлары да зур урын алган: баланың күзәтүчәнлеген үстерергә, табигатькә сакчыл караш тәрбияләргә ярдәм иткән.

Халык әкиятләре дә – яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә гаять әһәмиятле үрнәк-өлге булып тора. Каюм Насыйри халык әкиятләренең, бала тәрбияләүдәге роле ягыннан, хәтта балалар өчен махсус язылган башка әсәрләрдән югары торганлыгын ассызыклый, үзенең мәгърифәтчелек эшчәнлегендә алардан киң файдалана [9]. Әкият – бала өчен иң тәэсирле, иң кызыклы фольклор жанры. Чөнки ул бала белергә һәм өйрәнергә тиешле әдәп-әхлак кагыйдәләрен, кешелекнең рухи-мәдәни кыйммәтләрен тылсымлы мавыктыргыч сюжет кысаларына «төреп» бирә. Әкият нигезендә яткан үгет-нәсихәтне бала үзе дә сизмичә калебенә сеңдерә бара. «Татар халык әкиятләрен педагогик күзлектән тикшереп карау халкыбызның әле бик борынгы дәверләрдә үк бала тәрбияләү мәсьәләсенә җитди игътибар бирүен күрсәтә. Халык фикеренчә, тәрбиянең төп максаты – хезмәт сөюче, бернинди явыз көчләрдән курыкмаучы, аларга каршы көрәшергә әзер торучы, бөтен яктан да камил үсешкә ирешкән көчле шәхес тәрбияләү» [17, б. 27].

Тылсымлы әкиятләрдән аермалы буларак тормыш-көнкүреш әкиятләренең сюжеты гадилеге белән аерылып тора. Алар нигезендә – көндәлек, гадәти вакыйгалар ята. Халык әнә шул гадәти тормыш-көнкүреш хәлләре аша үзен борчыган проблемаларны күтәрә, үзенең хыяллары белән уртаклаша, яшь буынга үгет-нәсихәтен җиткерә. *«Мужик белән алпавыт», «Шомбай», «Көтүче Зариф»* кебек әкиятләрдә, халыкның гаделлек хакындагы идеаллары алга сөрелә, иҗтимагый-сәяси проблемалар күтәрелә. *«Калак та, таба да табылды», «Буразнада балык», «Мосафир», «Өч капчык сүз»* кебек әкиятләрдә исә, гаилә, ир белән хатын мөнәсәбәтләре яктыртыла, акыллылык, зирәклек, шаянлык кебек сыйфатлар мактала, наданлык, ахмаклык, ялкаулык кискен тәнкыйтьләнә, алар көлкегә алына.

Мондый әкиятләрдә шулай ук өлкән буынга хөрмәт, аларны акыл һәм зирәклек чишмәсе итеп карау *(«Зирәк карт», «Агай казны ничек бүлгән», «Карт белән ялкау егет»);* ялкаулык, саранлык сыйфатларын тәнкыйтьләү *(«Ике ялкау, «Комагай»);* хатын-кызларга хөрмәтне *(«Ярлы килен», «Акыллы килен», «Чибәр кыз Хәдичә»),* баланың ата-ана алдында бурычы, ата-ана васыятен тоту һ.б. бик күп проблемалар урын ала.

Аталар һәм балалар мөнәсәбәте татар әкиятләрендә шактый зур урын алып тора. Тылсымлы әкиятләрдә ата-ана образы бик зур җылылык һәм тирән хөрмәт белән тасвир ителә. Бу ихтирам – милләтебезнең асыл сыйфатларының берсе дәрәҗәсенә күтәрелә.

Әлеге әкиятләрдә халыкның идеал образы булып батыр егет сүрәтләнә, бу образ үрнәгендә яшь буынны, бигрәк тә ир балаларны, ятимнәрне яклаучы, мохтаҗларга ярдәм кулын сузучы, явыз җаннар белән көрәшүче, ил терәге булардай итеп тәрбияләгәннәр.

Бик еш кына гади халык арасыннан чыккан бу батыр егетләр үзләренең батырлыклары, кешелекле һәм акыллы булулары аркасында әкият ахырында зур дәрәҗәләргә ирешәләр, бәхетле гомер итәләр. «Халык әкиятләрендәге батырлар – элек-электән халкыбызның иң югары һәм иң гадел әхлак нормаларын бергә туплаган, тәрбия идеалын чагылдырган образлар алар. Халык аларны үзенең иң яхшы әдәп кагыйдәләренә нигезләнеп тудырган» [17, б. 30].

Әкиятләрдә балаларга дуслык, татулык, гаделлек, тугрылык хакында сөйли, үзеңдә яхшы сыйфатлар тәрбияләргә, авырлыклар алдында югалып калмаска өйрәтә *(«Өч күгәрчен», «Ак бүре», «Көнгә күренмәс Көмеш-Сылу» һ.б.).* Гомумән, әкиятләрдә халыкның киләчәк хакында, гаделлек, бәхет хакындагы өмет-хыяллары чагыла, тормыш-яшәеш кануннары турындагы фикерләре, һәръяктан камил инсан хакындагы уйлары урын ала. Халык яшь буынга үгет-нәсихәтен, тормыш тәҗрибәсен матур образлар, үтемле сүзләр, мавыктыргыч, тылсымлы сюжетлар аша мөмкин кадәр тәэсирле итеп җиткерергә тырыша. Шул рәвешчә, халык авыз иҗаты әсәрләре яшь буынга рухи-әхлакый тәрбия бирүдә, аның менталь-психологик дөньясын баетуда төп чараларның берсе булып тора.

Татар халык педагогикасының әһәмиятле состав өлешләренең берсе – гыйлем һәм мәгърифәткә хөрмәт тәрбияләү. Ш.Ш. Җәләлиев моны «акыл хезмәте мәдәнияте тәрбияләү» дип атый [3, б. 6] Гыйлемлелек һәм тәрбиялелек татар халкында элек-электән идеаль инсан образының аерылгысыз сыйфатлары саналган: *Белемдә көч. Дөньяда иң зур байлык – белем. Җиде йортның телен бел, Җиде төрле белем бел. Гыйлем дәрәҗәсе – дәрәҗәләрнең иң олысы.* Шуңа күрә хәтта бишек җырлары көйләгәндә дә аналар балаларына *«Әлли-бәлли итәр бу, Мәдрәсәгә китәр бу, анда галим булыр бу...»* дип теләкләр теләгәннәр. Шулай итеп, бишек җырларында ук балаларга белемгә мәхәббәт сеңдергән, балага үзенә күрә тормыш программасы салынган. Мәдрәсәдә укып чыккан яисә укучы өлкән туганнары кечкенәләргә үрнәк булган. Гыйлемлелек дөньясына беренче адымнарын ясаган балага

акрынлап, белемле булуның никадәр әһәмиятле икәнен мәкальләр аша төшендергәннәр: *Ата белеге белән адәм адәм булмас, әгәр үзе белмәсә.*

Халкыбызның хезмәт тәрбиясе тәҗрибәсе һәм хезмәт традицияләре, традицион һөнәрләре – милли үзаң тәрбияләүдә зур әһәмияткә ия факторларның берсе: «Чөнки аның тәрбия тәҗрибәсе борынгыдан ук әдәп-әхлакка корылган тормышына, хезмәт белән гадел көн күрүенә, бай педагогикасына нигезләнгән. Шуңа күрә халкыбыз үзе дә әхлаклы, шәфкатьле-мәрхәмәтле, хезмәт итә белә торган булуы белән танылган. Ул тәрбия асылын *«хәрәкәттә – бәрәкәт»* кебек тирән мәгънәле процесста күрә. *Хезмәт төбе сары алтын, Эше барның – ашы бар»* [3, б. 6]. Йөзләрчә ел дәвамында хезмәт тәрбиясе гаиләдә баланы тәрбияләүнең иң төп формаларының берсе булган. Ягъни хезмәт тәрбиясе рухи-әхлакый тәрбиянең нигезендә яткан. Татар халык педагогикасында хезмәтне ярату, тырышлык материаль гына түгел, ә бәлки рухи байлыкның да чыганагы буларак каралган [4, б. 67]. Хезмәт тәрбиясендә өлкән буын үрнәк, тәҗрибә, уртак хезмәт кебек ысулларны актив файдаланган. Бу тәрбияне тагын да нәтиҗәлерәк итәргә мөмкинлек биргән. Мисал өчен, кыз балалар кечкенәрәк вакытта, әниләренең, әбиләренең яисә апаларының төрле кул эше белән шөгыльләнгәннәрен күзәтәләр. Бераздан аларга да, кул һөнәрләренә өйрәтү максаты белән, яшьләренә туры китереп, орчык, каба һ.б. шундый кораллар ясап бирәләр, тегү-чигү, йон эрләү, туку кебек һөнәрләргә өйрәтергә керешәләр. Әниләр кызларына кечкенәдән үк аш-су серләрен төшендерә башлыйлар. Башта өлкәннәрнең өй эшләрен күзәткән бала, бераздан соң бу эшләрне әнисе яисә апасы, әбисе белән бергә эшли башлый. Уртак хезмәт процессында баланың хезмәт тәҗрибәсе байый, күнекмәләр формалаша, баланың теге як бу эшне үтәве шомара, тизләшә. Бераздан, әлеге эшләрне баланың үзенә генә башкарырга мөмкинлек бирәләр. Бу, бер яктан, зур җаваплылык булса, икенче яктан, шәхси тәҗрибәне баетуда, камилләштерүдә, мөстәкыйль фикер йөртә һәм ситуатив карарлар кабул итә белүдә зур адым була. Ир-балалар да, шул рәвешчә, өлкән буыннан хезмәт тәрбиясе ала. Балалар үсә барган саен, аларга йөкләнгән эшләрнең дә арта баруы күренә. Татар халкында баланы кече яшьтән әдәп-әхлакка, хезмәткә өйрәтергә кирәк, дигән караш яши: *Яшьлегеңдә өйрәнмәсәң, картлыгыңда үкенерсең. Яңа чагында киемеңне сакла, Яшь чагында исемеңне сакла. Ана сөте белән кергән онытылмый. Алтыдагы (холык) алтмышка. Ана баланы ике кат тудыра: Бер кат – тән биреп! Икенче кат – тел биреп! Атадан күреп ул үсә, Анадан күреп кыз үсә.*

Татар халык педагогикасы ислам тәгълиматы белән дә тыгыз керешеп-үрелеп килә. Ислам дине – рухи-әхлакый тәрбиянең нигезе, анда гомумкешелек кыйммәтләренең чагылышы, дини йолалар һәм өйрәтүләр, аларның халык тәрбиясендәге роле – татар халык педагогикасының гаять әһәмиятле элементы булып тора. Ислам халыкның тормыш-көнкүрешен билгеле бер кысаларда алып баруны, кешеләрнең үзара аңлашып, аралашып, фикер алышып яшәвен тәэмин итә. Исламдагы мәдәни, рухи-

əхлакый кыйммәтләр татар халык педагогикасын, ягъни аның тәрбия тәҗрибәсен баетуга зур өлеш кертә [3, б. 6–11]. Халык тәрбия тәҗрибәсендә һәм исламда бик үтемле, күпкырлы бай рухи мирас тупланган. Хәзерге яшьләрне əхлакый сау-сәламәт итеп үстерү өчен әлеге мирас бетмәс-төкәнмәс чыганак булып тора. Тик ул кыйммәтләрне дөрес һәм урынлы итеп, хәзерге яшәешне истә тотып, аңлатмалар белән тулыландырып файдалана белергә генә кирәк [14, б. 81].

Шул рәвешчә, халык педагогикасы яшь буында милли үзаң тәрбияләүнең төп чарасы булып тора. Бары тәрбиядәге халыкчанлык элементлары гына баланы яшьтән үк милли мөхиттә, милли тирәлектә тәрбияләү мөмкинлеге бирәләр. Халык педагогикасын тәрбия һәм белем бирүдә кулланып, без балаларда милли үзаң формалаштыру өчен табигый тирәлек тудырабыз. Бу, үз чиратында, буыннар арасында тәрбияви дәвамчанлыкны, милли педагогиканың иң яхшы традицияләрен сакларга, мөмкинлек бирә.

Гомумән, татар халкы элек-электән яшь буынның рухи-əхлакый, физик, хезмәт, гыйльми тәрбиясенә бик җитди игътибар иткән. Безнең ата-бабаларыбыз милләтне, рухи кыйммәтләрне бары милли үзаңы булган, формалашкан буын саклап калачагын яхшы аңлаган. Шул рәвешчә, халык педагогикасы нигезендә яткан гореф-гадәтләр, идеаллар, яшәү рәвеше, халыкның дөньяга карашы гасырлар дәвамында формалашып, җыеп-тупланып килгән. Ул – халыкның рухи-менталь табигатен чагылдыручы көзге. Халык педагогикасы «иҗтимагый аңның бик əһәмиятле һәм затлы чагылышы... анда халыкның зур тарихы, гыйбрәтле язмышы, үзенчәлекле психологиясе, үзенә генә хас сыйфатлары урын алган» [17, б. 6–7]. Шунысын да истә тоту мөһим: шәхес тәрбияләүдә халык педагогикасының барлык элементларыннан да урынлы һәм белеп файдаланырга, бу процесска комплекслы якын килергә кирәк. Бары шул чагында гына милли тәрбия көтелгән нәтиҗәне бирәчәк, бала күпкырлы үсешкә ирешкән, милли үзаңы булган гармоник шәхес буларак формалашачак. Бу эш өчен гаилә дә, уку йортлары да, тулаем җәмгыять тә җаваплы. Яшь буынга милли тәрбия бирү, аларда милли үзаңның ныклы платформасын булдыру – бөтен җәмгыятьнең күмәк хезмәте. Тәрбия процессында халыкның психологиясен, аның табигый үзенчәлекләрен белмәү, алар белән исәпләшмәү бары тик тискәре нәтиҗәләргә китерә ала. Бүген без җәмгыятьтә үз тамырларына, милли гореф-гадәтләргә кире кайту омтылышларын ачык күзәтәбез.

Мәңгелек универсаль кыйммәтләргә нигезләнгән татар милләтенең тәрбияви мирасы бу омтылышларга җавап бирерлек көч булып тора. Шулай ук ул балаларны гармоник үсешкә ирешкән шәхес буларак та тәрбияләү өчен кирәкле алымнар, карашларны да тәэмин итә ала. Бу байлыкны милләт тәррәкыяте өчен лаеклы, рухи һәм физик яткан сәламәт алмаш әзерләүдә дөрес һәм урынлы куллану көн кадагында торган актуаль проблемаларның берсе булып кала.

## ӘДӘБИЯТ

1. Афанасьев В.Ф. Этнопедагогика нерусских народов Сибири и Дальнего Востока. Якутск: Якутское книжное издательство, 1979. 180 с.

2. Волков Г.Н. Этнопедагогика. Чебоксары: Чувашское книжное издательство, 1974. 376 с.

3. Җәләлиев Ш.Ш. Милли тәрбия нигезләре: татар урта гомуми белем бирү мәктәпләре, педагогия колледжлары, училищелары өчен уку ярдәмлеге. Казан: Мәгариф, 2003. 149 б.

4. Зайдуллина Н.Н. Фольклорные традиции в трудовом воспитании // Вестник Университета Российской академии образования. М., 2007. № 3 (37). С. 66–67.

5. Измайлов А.Э. Народная педагогика: Педагогические воззрения народов Средней Азии и Казахстана. М.: Педагогика, 1991. 256 с.

6. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. 3 томда, 1 т. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1959. 916 б.

7. Латышина, Д.И., Хайруллин Р.З. Этнопедагогика: учебник для академического бакалавриата. 2-е изд., перераб. и доп. М.: Издательство Юрайт, 2014. 532 с.

8. Мирзоев Ш.А. Народная педагогика. Махачкала: Дагестанское учебно-педагогическое государственное издательство, 1984. 112 с.

9. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда, 3 т. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005. 384 б.

10. Нездемковская Г.В. Становление этнопедагогики в России // Вестник Томского государственного университета. Томск, 2009. № 326. С. 186–193.

11. Тукай Г. Халык әдәбияты. Казан: Татарское государственное издательство, 1946. 100 б.

12. Ушинский К.Д. Педагогические сочинения. В 6 т. Т. 1. М.: Педагогика, 1988. 416 с.

13. Хакимов Р.Э. Этнопедагогика как наука: предмет, функции, основные категории // Вестник Удмуртского государственного университета. 2007. № 9. С. 39–52.

14. Халиков И.Ю. Татар халкының педагогик фикере үсешендә ислам кыйммәтләре. Казан: ТФА Ш.Мәрҗани ис. Тарих институты, 2010. 124 б.

15. Ханбиков Я.И. Из истории педагогической мысли татарского народа. Казань: Татарское книжное издательство, 1967. 157 с.

16. Чапаев Н.К. Народная педагогика как интеллектуально-духовная основа научной педагогики // Этнопедагогические традиции формирования культуры межнациональных отношений. Казань: КГПУ, 2000. 216 с.

17. Шәймәрдәнов Р.Х., Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Татар милли педагогикасы. Казан: Мәгариф, 2007. 399 б.

18. Шаймарданов Р.Х., Сибгатуллин Р.Г. Татарская народная педагогика. Казань: Дом печати, 2000. 392 с.

19. Ялалов Ф.Г. Этнодидактика. М.: Гуманитарный издательский центр ВЛАДОС, 2002. 151 с.

**Автор турында белешмә:** Яруллина Ләйсән Илсур кызы – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш.Мәрҗани ис. Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге өлкән фәнни хезмәткәре (420014, Кремль, 5 нче подъезд, Казан, Россия Федерациясе); liysan-jarullina@mail.ru

## НАРОДНАЯ ПЕДАГОГИКА – ФАКТОР ФОРМИРОВАНИЯ НАЦИОНАЛЬНОГО САМОСОЗНАНИЯ

***Л.И. Яруллина***

*Институт истории им. Ш.Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*liysan-jarullina@mail.ru*

В статье анализируется роль народной педагогики в формировании национального самосознания. В работе рассматриваются взгляды ученых по определению таких понятий, как «этнопедагогика», «народная педагогика», «национальное воспитание», «национальное самосознание», отмечается актуальность исследований в данных направлениях. Автор, принимая во внимание многогранность и многоаспектность данных явлений, в качестве основных видов формирования национального самосознания выделяет фольклор, умственное, духовное, эстетическое, трудовое, физическое, религиозное воспитание. Подчеркивает необходимость комплексного подхода для воспитания гармоничной многогранной личности.

**Ключевые слова:** народная педагогика, этнопедагогика, национальное самосознание, духовные ценности, фольклор, духовное, умственное, религиозное, трудовое, национальное воспитание, эмпирические знания, опыт

**Сведения об авторе:** Яруллина Ляйсан Ильсуровна – кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Центра истории и теории национального образования Института истории им. Ш.Марджани Академии наук Республики Татарстан (420014, Кремль, подъезд 5, Казань, Российская Федерация); liysan-jarullina@mail.ru

## FOLK PEDAGOGY – A MEANS OF INSTILLING NATIONAL CONSCIOUSNESS

***L.I. Yarullina***

*Sh.Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*liysan-jarullina@mail.ru*

The article is devoted to the analysis of the role of folk pedagogy in the formation of national identity. It examines the views of scholars regarding how to define terms such as «pedagogy», «folk pedagogy», «national education», and «national identity»,

likewise emphasizing the importance of conducting research in these areas. By taking into account the complexity and multidimensional nature of these phenomena, the author highlights folklore and work ethic, as well as mental, spiritual, aesthetic, physical and religious upbringing as the main influences on the formation of national identity. Stress is placed on the need for an integrated approach to the education of the harmoniously developed personality.

**Keywords:** education, empirical knowledge, ethnopedagogy, experience, family education, folk pedagogy, folklore, moral upbringing, national identity, spiritual values

REFERENCES

1. Afanas'ev V.F. *Etnopedagogika nerusskikh narodov Sibiri i Dal'nego Vostoka* [Ethnopedagogy of the Non-Russian Peoples of Siberia and the Far East]. Yakutsk, Yakut book publishing house, 1979. 180 p.

2. Volkov G.N. *Etnopedagogika.* [Ethnopedagogy]. Cheboksary, Chuvash book publishing house, 1974. 376 p.

3. Җәləliev Sh.Sh. *Milli tərbiya nigezlərе: tatar urta gomumi belem birү məktəplərе, pedagogiya kolledzhlary, uchilishchelary өchen uku yardəmlege* [The Foundations of National Education: The Textbook for Tatar Secondary Schools and Pedagogical Colleges]. Kazan, Məgarif Publ., 2003. 149 p.

4. Zaydullina N.N. Fol'klornye traditsii v trudovom vospitanii [Folklore Traditions in Labor Education]. *Vestnik Universiteta Rossiyskoy akademii obrazovaniya – The Bulletin of the University of the Russian Academy of Education*. Moscow, 2007, no.3 (37), pp. 66–67.

5. Izmaylov A.E. *Narodnaya pedagogika: Pedagogicheskie vozzreniya narodov Sredney Azii i Kazakhstana* [National Pedagogy: Pedagogical Views of the Peoples of Central Asia and Kazakhstan]. Moscow, Pedagogika Publ., 1991. 256 p.

6. Isənbət N. *Tatar khalyk məkal'lərе* [The Tatar National Proverbs]. Kazan, Tatar book publishing house, 1959, vol. 1. 916 p.

7. Latyshina D.I., Khayrullin R.Z. *Etnopedagogika: uchebnik dlya akademicheskogo bakalavriata* [Ethnopedagogy: Textbook for the Bachelor's Degree]. Moscow, Yurayt Publ., 2014. 532 p.

8. Mirzoev Sh.A. *Narodnaya pedagogika* [National Pedagogy]. Makhachkala, Dagestan Educational-Pedagogical State Publishing House, 1984. 112 p.

9. Nasyyri K. *Saylanma əsərlər* [Selected Works]. Kazan, Tatar Book Publishing House, 2005, vol. 3. 384 p.

10. Nezdemkovskaya G.V. Stanovlenie etnopedagogiki v Rossii [The Formation of Ethnopedagogy in Russia]. *Vestnik Tomskogo gosudarstvennogo universiteta – The Bulletin of Tomsk State University*. Tomsk, 2009, no. 326, pp. 186–193.

11. Tukay G. *Khalyk ədəbiyaty* [The People's Literature]. Kazan, Tatar State Publishing House, 1946. 100 p.

12. Ushinskiy K.D. *Pedagogicheskie sochineniya* [Pedagogical Essays]. Moscow, Pedagogika Publ., 1988, vol. 1, 416 p.

13. Khakimov R.E. Etnopedagogika kak nauka: predmet, funktsii, osnovnye kategorii. [Ethnopedagogics as a science: subject, functions, main categories]. *Vestnik Udmurtskogo gosudarstvennogo universiteta – The Bulletin of Udmurt State University*, 2007, no. 9, pp. 39–52.

14. Khalikov I.Yu. *Tatar khalkynyң pedagogic fikere yseshendə islam kyymmət-lərе* [Islamic Values in the Tatar People's Pedagogical Ideas]. Kazan, Sh.Marjani Institute of History Publ., 2010. 124 p.
15. KhanbikovYa.I. *Iz istorii pedagogicheskoy mysli tatarskogo naroda* [From the History of Pedagogical Thought of the Tatar People]. Kazan, Tatar book publishing house, 1967. 157 p.
16. Chapaev N.K. Narodnaya pedagogika kak intellektual'no-dukhovnaya osnova nauchnoy pedagogiki [National Pedagogy as an Intellectual and Spiritual Foundation for Scientific pedagogy]. *Etnopedagogicheskie traditsii formirovaniya kul'tury mezhnatsional'nykh otnosheniy* [Ethnopedagogical Traditions in the Formation of Culture in Interethnic Relations]. Kazan, Kazan State Pedagogical University, 2000. 216 p.
17. Shəymərdənov R.Kh., Khuҗiəkhmətov Ə.N. *Tatar milli pedagogikasy* [Tatar National Pedagogy]. Kazan, Məgarif Publ., 2007. 399 p.
18. Shaymardanov R.Kh., Sibgatullin R.G. *Tatarskaya narodnaya pedagogika* [Tatar National Pedagogy]. Kazan, Publishing house, 2000. 392 p.
19. Yalalov F.G. *Etnodidaktika* [Ethnodidactics]. Moscow, Humanitarian Publishing Center VLADOS Publ., 2002. 151 p.

**About the author:** Lyaysan I. Yarullina – Candidate of Science (Philology), Senior Research Fellow, Center of History and Theory of National Education, Sh.Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (Entrance 5, Kremlin, Kazan 420014, Russian Federation); liysan-jarullina@mail.ru